**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 44**

Мөслим авылы «26» август 2021 ел

**Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турында**

«Мөслим муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында» Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре карарлары нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә авыл җирлекләре бюджетларыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән Мөслим муниципаль районы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшыру турында килешү төзергә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин